Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Иске Иштирәк авыл җирлеге
Иске Иштирәк авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Иске Иштирәк авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, II төркем инвалидлар, көндезге уку формалары студентлары (укучылары) тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- җирлекнең су үткәрү мөлкәтен ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә бирелгән вәкаләтләр нигезендә суүткәргеч мөлкәтен карап тоту;
- урамнарны яктыртуны оештыру;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту;
-Иске Иштирәк авылында җирле әһәмияттәге юлларга вак таш җәю;
- җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 363 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 184 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Иске Иштирәк авылында гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Иске Иштирәк авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, II төркем инвалидлар, көндезге уку формалары студентлары (укучылары) тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- җирлекнең су үткәрү мөлкәтен ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә бирелгән вәкаләтләр нигезендә суүткәргеч мөлкәтен карап тоту;

- урамнарны яктыртуны оештыру;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту;
-Иске Иштирәк авылында җирле әһәмияттәге юлларга вак таш җәю;
- җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү карарны кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 5, Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27, Бәкер авылы, Нагорная, 38 адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Иштирәк авыл җирлеге башлыгы А.А.Вәлиәхмәтов